ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 19.08.2026 1233 КАРАР

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә бер яки берничә муниципаль даими йөртү муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм йөк ташуны гамәлгә ашыруга таныклык алу хокукына ачык конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 2126 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә бер яки берничә муниципаль даими йөртү муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм йөк ташуны гамәлгә ашыруга таныклык алу хокукына ачык конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 2126 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның бөтен тексты буенча «пассажирлар йөртүне һәм йөк ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык» сүзләрен тиешле килешләрдә «пассажирлар йөртүне һәм йөк ташуны гамәлгә ашыру хокукы» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. карарның бөтен тексты буенча «таныклык» сүзләрен тиешле килешләрдә «хокук» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. Нигезләмәнең 10 бүлеген түбәндәге эчтәлекле 10.7 пункты белән тулыландырырга:

«10.7. Пассажирлар йөртүне һәм йөк ташуны гамәлгә ашыру хокукының аерылгысыз өлеше булган маршрут карталары, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең ярдәм системасыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә төзелә һәм рәсмиләштерелә, шулай ук мөрәҗәгать итүче гаризасы буенча кәгазь документ рәвешендә бирелергә мөмкин. Вәкаләтле вазифаи затның квалификацияле электрон имзасы булганда маршрут картасының электрон версиясе кәгазь версиясе белән бертигез юридик көчкә ия».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзекләндерү һәм инфраструктура

үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.А. Томилин

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 00EF64EBB949F1A987030464884AC8DB87

Владелец: Томилин Андрей Александрович

Действителен с 22.12.2025 до 17.03.2027